ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Зур Кызыл ур. 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 151

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«03» август 2020 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25 декабрендәге 479 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба – Административ регламент) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы (Воронская Н.Н.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А.Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның «03» август 151 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.4 пунктта:

икенче абзацта 1.1, 5.2 саннарын төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР ДТИ рәсми сайтында (https://gji.tatarstan.ru). Рәсми сайтта мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла, әлеге Административ регламентның 1.3, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;»;

1.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) «Интернет» челтәрендә ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)). Гаризаларның формалары әлеге Регламентка 1, 2, 3, 4 нче кушымталарда китерелгән.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «99-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләрен «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон)» дигән сүзләргә, «РФ Торак кодексы» сүзләрен «Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы)» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Нигезләмә» сүзен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «1110 номерлы нигезләмә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында» 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә (алга таба – 1110 номерлы нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы

исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

2.9 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «РФ Салым кодексы» сүзләрен «Россия Федерациясе Салым кодексы» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «РФ Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентның 5 бүлегендәге атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».